# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**25 ноябрь 2022 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 150 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Карамалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Карамалы авылында урамнарны яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны, электр товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуга агымдагы ремонт һәм хезмәт күрсәтү);
- Җәйге чорда территорияне чаптыру (ГСМ, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Карамалы авылында юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яца ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», Халыкара өлкәннәр көне» нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу;
- Карамалы авылында Профсоюз урамында зират территориясен киртәләү өчен материаллар (төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) алу;
- Күмү урыннарын карап тоту (агачларны кисү, куакларны кисү, үлән чаптыру, чүп-чар җыю, триммер, инструментлар һәм җиһазлар сатып алу).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге башлыгы — А.Р. Ногманов